**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

24 сентябрь 2018ел №154

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында.

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 13 статьясы, «Җирле референдумны үткәрүне инициацияләү турында» 2018 елның 20 сентябрендәге 153 номерлы Норлат авыл җирлеге Советы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2018 елның 18 ноябренә Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2.Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

"2019 елда Норлат авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә сез килешәсезме:

2.1. Җирлек чикләрендә автомобиль юлларын, күпер корылмаларын ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту, инертлы материаллар сатып алу;

2.2. Су белән тәэмин итү, су чыгару һәм коелар челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту;

2.3. Урам яктыртуын ремонтлау, карап тоту һәм паспортлаштыру, шул исәптән чыгым материалларын һәм комплектлаучыларны сатып алу;

2.4. Территорияне (һәйкәлләрне, зиратларны, контейнер мәйданчыкларын, санкцияләнмәгән чүплекләр, чишмәләр, балалар һәм спорт мәйданчыкларын төзү, карап тоту (төзекләндерү), тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау, шул исәптән әлеге максатлар өчен төзелеш материаллары һәм кече архитектура формаларын сатып алу;

2.5.Урамнарны һәм тышкы төзекләндерү объектларын техник паспортлаштыру;

2.6.смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру.

«ӘЙЕ» «ЮК».».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырыр һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин ур., 46 йорт (административ бина), Норлат авылы, М.Фәйзуллин ур., 17 йорт (ЦКС "Заволжье" бинасы) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

**Норлат авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе Р.Р.Багаутдинов**